ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.09.2026 1358 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамәләр төзү хокукына аукцион оештыру (әзерләү) һәм үткәрү комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамәләр төзү хокукына аукцион оештыру (әзерләү) һәм үткәрү комиссиясе турындагы Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион оештыру һәм үткәрү комиссиясе составын 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин

ЕМСЭД
**Республики Татарстан**
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 7C878CC2715BCC42F14A435C46E05934
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 27-08-2026 до 20-11-2027

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамәләр төзү хокукына аукцион оештыру (әзерләү) һәм үткәрү комиссиясе турында Нигезләмә**

**1 нче бүлек**

**Гомуми нигезләмәләр**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамәләр төзү хокукына аукцион оештыру (әзерләү) һәм үткәрү комиссиясе (алга таба - Комиссия), Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамәләр төзү хокукына электрон аукционнар (алга таба - аукцион) оештыру һәм уздыру өчен төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Граждан кодексына таяна.

3. Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

3.1. аукционда катнашуга мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан бирелгән гаризалар документларга теркәп бирелә һәм бергә карала;

3.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2026 елның 29 июнендәге 1074 номерлы карары нигезендә мөрәҗәгать итүчеләрне аукционда катнашуга кертү турында яисә аукцион турындагы нигезләр һәм документлар буенча аукционда катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә;

3.3. йомгак ясый һәм аукцион җиңүчесен билгели; 3.4. утырышларның беркетмәләрен төзи һәм имзалый; 3.5. аукцион үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1. билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук профильле оешмалардан һәм предприятиеләрдән аукцион оештыру һәм уздыру өчен кирәкле мәгълүматны, шул исәптән материалларны һәм документларны сорарга һәм соратып алырга;

4.2. комиссия утырышларын үткәрергә, комиссия компетенциясендәге барлык мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә һәм язышырга;

4.3. мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларны бәяләү өчен бәйсез экспертларны Россия Федерациясе законнарында һәм Алабуга муниципаль

районы Башкарма комитетының эчке актларында билгеләнгән тәртиптә чакырырга.

5. Комиссиянең эш тәртибе:

5.1. Комиссия составы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2. Комиссияне комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итүче рәис җитәкчелек итә.

5.3. Комиссия рәисе булмаган чорда аның вазифаларын комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

5.4. Комиссия утырышлары комиссия составына керүче затларның кимендә 50 проценты катнашса, хокуклы.

5.5. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхсән катнашалар һәм комиссия утырышлары беркетмәләренә визалар ясыйлар.

5.6. Комиссия секретаре комиссия утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә, утырышлар беркетмәләрен әзерли.

5.7. Комиссия карарлары:

5.7.1. аукционда катнашу өчен гаризаларны карау нәтиҗәләре турында карар (гариза бирүчеләрне катнашуга кертү яки катнашуга кертүдән баш тарту турында) утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә;

5.7.2. тавыш тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора;

5.7.3. аукцион нәтиҗәләре турында карар аукцион нәтиҗәләреннән чыгып кабул ителә;

5.6.4. комиссия карарлары, шул исәптән аукционда катнашу өчен гаризаларны карау нәтиҗәләре, аукцион нәтиҗәләре, җиңүчене билгеләү һәм башкалар турында карарлар комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

6. Комиссия эшчәнлегенең оештыру мәсьәләләре:

6.1. Комиссия эшчәнлеген оештыру аукционны оештыручы тарафыннан башкарыла.

6.2. Комиссия секретаре комиссия утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә, утырыш беркетмәләрен һәм башка документларны рәсмиләштерә.

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына 2 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион оештыру һәм үткәрү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| 1. Комиссия рәисе | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2. Комиссия рәисе урынбасары | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеше буенча урынбасары |
| 3. Комиссия секретаре | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү секторы мөдире |
| 4. Комиссия әгъзасы | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |
| 5. Комиссия әгъзасы | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |